**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 17 март

№ 157

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1054 нче карары белән расланган 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2013 ел, 25 декабрь, 1054 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 318 нче; 2014 ел, 17 июль, 511 нче; 2014 ел, 25 декабрь, 1028 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1076 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына 2 нче кушымта

## 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфаты һәм аның һәркем алырлык булу критерийларының максатчан мәгънәләре

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Максатчан күрсәткеч | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **2014 ел** | **2015 ел** | **2016 ел** |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Халыкның медицина ярдәменнән канәгать булу-булмавы, шул исәптән: | сораштырылганнар саныннан процент | 51,0 | 51,5 | 52,0 |
| шәһәр халкы | | 58,2 | 58,7 | 59,2 |
| авыл халкы | | 48,1 | 48,6 | 50,0 |
| Халык үлеме күрсәткече, шул исәптән: | 1000 кешегә үлүчеләр саны | 12,0 | 11,8 | 11,6 |
| шәһәр халкы | | 11,0 | 10,8 | 10,6 |
| авыл халкы | | 16,2 | 16,0 | 15,8 |
| Кан әйләнеше системасы авыруларыннан халыкның үлеме күрсәткече, шул исәптән: | 100 мең кешегә кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны | 660 | 655 | 650 |
| шәһәр халкы | | 602,0 | 590,0 | 580,0 |
| авыл халкы | | 800,2 | 790,2 | 780,0 |
| Шешләрдән, шул исәптән яман шешләрдән, халыкның үлеме күрсәткече: | 100 мең кешегә шешләрдән (шул исәптән яман шешләрдән) үлүчеләр саны | 182,7 | 182,6 | 182,5 |
| шәһәр халкы | | 180,7 | 180,5 | 180,4 |
| авыл халкы | | 179,6 | 179,5 | 179,4 |
| Халыкның туберкулездан үлеме күрсәткече, шул исәптән: | 100 мең кешегә туберкулездан үлүчеләр саны | 6,2 | 6,1 | 6,0 |
| шәһәр халкы | | 7,1 | 7,1 | 7,0 |
| авыл халкы | | 6,0 | 6,0 | 6,0 |
| Эшкә яраклы яшьтәге кешеләр үлеме күрсәткече | 100 мең кешегә эшкә яраклы яшьтә үлүчеләр саны | 494,3 | 494,0 | 493,5 |
| Эшкә яраклы яшьтәге халыкның кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлеме күрсәткече | 100 мең кешегә эшкә яраклы яшьтә кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны | 180,5 | 179,5 | 177,0 |
| Аналар үлеме күрсәткече | тере туган 100 мең кешегә | 10,6 | 10,5 | 10,4 |
| Сабыйлар үлеме күрсәткече | тере туган 1000 кешегә | 6,9 | 6,8 | 6,7 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 0 - 4 яшьтәге балалар үлеме күрсәткече | тиешле яшьтәге 100 мең кешегә | 188,7 | 188,7 | 188,2 |
| 0 – 17 яшьтәге балалар үлеме күрсәткече | тиешле яшьтәге 100 мең кешегә | 80,0 | 79,5 | 79,0 |
| Исәптә торучы яман шеш авырулы пациентларның гомуми санында диагноз куелган вакыттан алып 5 ел һәм аннан да күбрәк вакыт исәптә торучы яман шеш авырулы пациентлар өлеше | % | 53,9 | 54,1 | 54,3 |
| Халыкның табиблар белән тәэмин ителеше – барлыгы, | 10 мең кешегә | 29,5 | 29,8 | 30,1 |
| шул исәптән медицина ярдәме күрсәтүче: | | | | |
| амбулатория шартларында | 10 мең кешегә | 15,9 | 16,0 | 16,1 |
| стационар шартларда | 10 мең кешегә | 11,7 | 11,7 | 11,7 |
| Халыкның урта медицина персоналы белән тәэмин ителеше – барлыгы, | 10 мең кешегә | 89,8 | 89,4 | 89,1 |
| шул исәптән медицина ярдәме күрсәтүче: | | | | |
| амбулатория шартларында | 10 мең кешегә | 39,6 | 39,7 | 39,8 |
| стационар шартларда | 10 мең кешегә | 37,4 | 37,3 | 37,2 |
| Стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында дәвалану вакытының уртача озынлыгы | койка-көн | 11,0 | 10,9 | 10,8 |
| Медицина оешмалары (шул исәптән шәһәр һәм авыл җирендә урнашкан) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге, түбәндәгеләр нигезендә: | | | | |
| табиб вазыйфасы функциясен үтәүне бәяләү | процент | 95,0 | 96,0 | 96,0 |
| койка фондыннан рациональ һәм максатчан файдалану күрсәткечләре | көн | 348 | 347 | 348 |
| 2014 елга, 2015 һәм 2015 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) барлык чыгымнарда көндезге стационар- | процент | 8,3 | 8,4 | 8,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| лар шартларында медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнар өлеше | | | | |
| Программага барлык чыгымнарда амбулатория шартларында кичектергесез формада медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнар өлеше | процент | 1,2 | 1,2 | 1,2 |
| Пргограммага барлык чыгымнарда паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнар өлеше | процент | 0,096 | 0,096 | 0,096 |
| Беренче тапкыр яман шеш авырулары ачыкланган пациент-ларның гомуми санында башланып килгән стадияләрендә ачыкланган яман шеш авырулы пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 54,4 | 54,5 | 54,6 |
| Балаларны (шул исәптән авыл һәм шәһәр җирендә яшәүче) профилактика медицина тикше-рүләренә җәлеп итүнең тулылыгы | процент | 50 дән ким түгел | 50 дән ким түгел | 50 дән ким түгел |
| Мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы кыса-ларында стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтелгән пациентларның гомуми санында федераль медицина оешмала-рында стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме алган пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 0,9 | 1,0 | 1,1 |
| Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтелгән авыл җирендә яшәүче затлар саны | 1000 авыл кешесенә | 142,0 | 142,0 | 142,0 |
| Фельдшерлык-акушерлык пунктларының һәм фельдшерлык пунктларының гомуми санында авария хәлендәге һәм капиталь ремонт таләп ителәә торган фельдшерлык-акушерлык пункт-лары һәм фельдшерлык пункт-лары өлеше | процент | 14 | - | - |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Чакыруларның гомуми санында чакырган вакыттан кимендә 20 минут эчендә пациент янына килеп җиткән ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү бригадалары бару өлеше | процент | 85,5 | 86,4 | 87,2 |
| Диспансеризация үтәргә тиешле 18 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк затларның (шул исәптән шәһәр һәм авыл җирендә яшәүче) гомуми санында диспансеризация үткән 18 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затларның чагыштырма авырлыгы | процент | 60,0 | 60,0 | 60,0 |
| Миокард инфаркты белән госпитальләштерелгән пациентларның гомуми санында авырый башлаган беренче 6 сәгать эчендә госпитальләштерелгән миокард инфаркты белән авыручы пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 50 | 51 | 52 |
| Көчле миокард инфаркты белән авыручы пациентларның гомуми санында тромболитик терапия үткәрелгән пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 11,4 | 12,1 | 12,4 |
| Көчле миокард инфаркты белән авыручы пациентларның гомуми санында коронар артерияләренә стентлау үткәрелгән көчле миокард инфаркты белән авыручы пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 25,0 | 25,5 | 26,0 |
| Ашыгыч медицина ярдәменең күчмә бригадалары тарафыннан медицина ярдәме күрсәтелгән көчле һәм кабатланган миокард инфаркты белән авыручы 100 пациентка исәпләгәндә ашыгыч медицина ярдәменең күчмә бригадалары тарафыннан үткәрелгән тромболизислар саны | процент | 3,6 | 3,8 | 4,0 |
| Көчле цереброваскуляр авы-рулар буенча госпитальләш-терелгән пациентларның гомуми санында авырый башлаган беренче 6 сәгать эчендә госпиталь- | процент | 30,0 | 32,0 | 34,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| ләштерелгән цереброваскуляр авырулы пациентлар санының чагыштырма авыр-лыгы | | | | |
| Көчле ишемия инсульты белән авыручы пациентларның гомуми санында госпитальләштергәндә беренче 6 сәгать эчендә тром-болитик терапия үткәрелгән көчле ишемия инсульты белән авыручы пациентлар санының чагыштырма авырлыгы | процент | 1,5 | 1,8 | 2,0 |
| Нигезле шикаятьләр саны, шул исәптән Программа кысала-рында күрсәтелә торган медицина ярдәмен күрсәтүдән баш тартуга карата | 10 000 кешегә бердәмлегенә | 1,0 | 0,9 | 0,8». |

2. Бу карарның гамәле 2014 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\157.doc